**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **27 ноябрь 2020 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче
Митрәй авылында 2021 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Митрәй авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2021 елда Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Митрәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Митрәй авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Митрәй авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү;
- Митрәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Митрәй авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Митрәй авылы урамнарына вак таш түшәлгән юлларны ремонтлау һәм карап тоту (сатып алу, ташу, вак таш җәю, билгеләр кую, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру (Митрәй авылы зиратларында контейнерларга каты өслек урнаштыру, чүп-чар өчен контейнерлар сатып алу);

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Митрәй авылы, Тукай ур.,15А йорт
кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы Идрисов З.Ә.